РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

с. Тюлячи

КАРАР

«20» январь 2023г.

№ 7

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 27 декабрендәге 804 номерлы «Теләче муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру турындагы Нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә мәҗбүри таләпләр турында» Федераль законның 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 24 сентябрендәге 371-ФЗ номерлы Федераль закон, «Вөҗдан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Федераль законның 19 статьясына һәм «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 29 декабрендәге 641-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 27 декабрендәге 804 номерлы «Теләче муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына (15.06.2020 № 259 карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- күрсәтелгән карар белән расланган Төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне, шулай ук Теләче муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне оештыру турында нигезләмәгә:

- 3.11 пунктта «яисә тиешле белем бирү программасы буенча дәүләт аккредитациясенең гамәлдә булу срогы тәмамлану» сүзләрен «дәүләт аккредитациясенең гамәлдә булуы тукталу» сүзләренә алмаштырырга;

- 4.7 пунктта «мәктәпкәчә белем бирүнең тиешле якынча белем бирү программаларын исәпкә алып» сүзләрен «мәктәпкәчә белем бирүнең тиешле

федераль белем бирү программасы» сүзләренә алмаштырырга, түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Белем бирү программаларының мәгариф оешмалары тарафыннан эшләнгән эчтәлеге һәм планлаштырыла торган нәтиҗәләре мәктәпкәчә белем бирүнең федераль программасының тиешле эчтәлегеннән һәм планлаштырылган нәтиҗәләреннән түбәнрәк булмаска тиеш.».

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин